**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**БОЕРЫГЫ**

14.09.2018 № 306

**Татарстан Республикасы Президентының «Хокукый мәгълүмат рәсми интернет-порталында» (www.pravo.gov.ru) Татарстан Республикасы законнарын һәм башка хокукый актларын урнаштыруның (бастырып чыгаруның) аерым мәсьәләләре турында» боерыгына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы Президентының «Хокукый мәгълүмат рәсми интернет-порталында» (www.pravo.gov.ru) Татарстан Республикасы законнарын һәм башка хокукый актларын урнаштыруның (бастырып чыгаруның) аерым мәсьәләләре турында» 2015 елның 26 мартындагы 235 номерлы боерыгына, 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«2. Татарстан Республикасы юстиция министры Рөстәм Илдус улы Заһидуллинга Россия Федерациясе федераль сак хезмәте белән Татарстан Республикасы законнары һәм башка хокукый актлары контроль нөсхәләренең электрон образларын даими нигездә тапшыру һәм аларны Порталда урнаштыру (бастырып чыгару) мәсьәләләре буенча хезмәттәшлек регламентын, шулай ук әлеге регламентка кертелә торган үзгәрешләрне раслау вәкаләтләрен бирергә.».

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ